| | |
|---|---|
| ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ<br>ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>ШӘҺӘР СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

7 апрель, 2016 ел № 7/9

Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлегенең топонимика буенча
комиссия составын раслау турында

Шәһәр Уставының 28, 52 маддәләре нигезендә
Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең топонимика буенча комиссия составын кушымтадагыча расларга.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

1) Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/12 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең топонимика буенча комиссия составы;

2) Шәһәр Советының 2008 елның 25 декабрендәге «Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең топонимика буенча комиссиясе турында» 19/12 санлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында» 37/8 санлы Карары;

3) Шәһәр Советының 2009 елның 18 июнендәге «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең топонимика буенча комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында» 41/13 санлы Карары («Челнинские известия» газетасының 2009 елның 24 июнендәге 117-118 саннарында басылган);

4) Шәһәр Советының 2012 елның 20 апрелендәге «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең топонимика буенча комиссиясе Составына үзгәрешләр кертү хакында» 18/23 санлы Карары;

5) Шәһәр Советының 2014 елның 10 июлендәге «Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/12 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең топонимика буенча комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында» 31/19 санлы Карары;

6) Шәһәр Советының 2015 елның 23 июлендәге «Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/12 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең топонимика буенча комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында» 41/6 санлы Карары.

2. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Шәһәр Советының
7/9 нчы Карарына кушымта
7 апрель, 2016 ел

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең топонимика буенча комиссия составы

| | |
|---|---|
| Абдуллин Ринат Әзһәр улы | – комиссия рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе; |
| Хәлимов Рамил Мәрвән улы | –Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары вазифаларын башкаручы, мәгариф һәм яшьләр эшләре буенча идарә башлыгы |
| Комиссия | әгъзалары: |
| Батюшов Әбделхак Мостафа улы | –Шәһәр Советы депутаты, мәгариф, мәдәният, милли мәсьәләләр, яшьләр эшләре һәм спорт буенча даими комиссия рәисе, «СТВ-МЕДИА» холдингы генераль директоры; |
| Вафин Рәфыйк Нургаяз улы | –Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте Башлыгы урынбасары; |
| Зарипов Рамил Камил улы | –Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте Башлыгы урынбасары; |
| Канеев Билял Абдрахманович | – «Яр Чаллы шәһәре музее» муниципаль автоном мәдәният учреждениесенең һәйкәлләрне саклау буенча өлкән фәнни хезмәткәре (килешү буенча); |
| Петров Альберт Николаевич | –Шәһәр Советы депутаты, шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссия әгъзасы, «КамГЭСэнергострой» капиталь төзелеш идарәсе ҖЧҖ генераль директоры; |

| | |
|---|---|
| Рзаева Гөлзадә Мөхәммәтгәрәй кызы | – «Энергетик» мәдәният йорты муниципаль автоном мәдәният учреждениесенең директор урынбасары, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, шәһәрнең мактаулы гражданы (килешү буенча); |
| Сәлмәнов Ленар Ирек улы | – «Шәһәр төзелеше үсеше хезмәте» МУП директоры; |
| Сафин Факил Миңнемөхәммәт улы | – «Көмеш кыңгырау» газетасының баш редакторы, Язучылар берлегенең Яр Чаллы бүлеге рәисе Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре (килешү буенча); |
| Ситдыйков Салават Әнәс улы | – Башкарма комитетның Үзәк районы хакимияте Башлыгы урынбасары; |
| Хайман Татьяна Александровна | – «Кама-Дизайн» Россия дизайнерлары берләшмәсенең Яр Чаллы оешмасы рәисе (килешү буенча); |
| Шәрипов Әнвәр Мәгъдәнур улы | – филология фәннәре докторы, Яр Чаллы педагогика университеты профессоры (килешү буенча). |